# ӘТКӘЙГӘ СӘЛАМ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Күпме сүзләр, изге теләкләр
Шигырь булып, иңгән матур көйләргә!
Без аларга кушып саф күңел хисләрен,
Сәлам юллыйбыз әткәйләргә!

**Кушымта:**

Сәлам сиңа, әткәй, йөрәкләр түреннән!
Сәлам сиңа кызлар-уллардан!
Саклый күрсен Ходай сине җилләреннән,
Саклый күрсен авырулардан!

Нурлы көннәр белән тыныч төннәр теләп,
Рәхмәт әйтә сиңа балаларың –
Еллар буе эшләп түккән тирең белән
Сугарылып үскән гөлләрең.

2. Кырыс идең, әткәй, шулай да
Безнең өчен янды, көенде бәгырең.
Сирәк иде, ләкин бигрәк татлы иде
Безне иркәләп сөюләрең!

**Кушымта.**

3. Үстек, әткәй, бастык аякка,
Уку еллары да артта калдылар,
Ләкин безнең өчен гади киңәшләрең
Иң кыйммәтле сабак булдылар!

**Кушымта.**

**Привет отцу**

Песня написана ко дню рождения моего отца Шавката Гарифжановича Сагаутдинова. Посвящается всем отцам.

*Привет тебе, отец, из тайников сердечных!*
*С приветом словно сам к тебе лечу я!*
*За радость, за любовь, за негу дней беспечных –*
*За всё благодарить тебя хочу я!*